**СОВЕТ РОЖДЕСТВЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422631д.Дятлово,
ул. Юности, д.1
тел: 4-74-98

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ РОЖДЕСТВЕНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422631 Дятлово авылы,
Яшьлек урамы, 1 нчы йорт,
тел: 4-74-98

---

**2023 елның 23 ноябре** **187 номер**

**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Рождествено авыл җирлегенең Тәнгәчи торак пунктында гражданнар җыены карары**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Лаеш муниципаль районының Рождествено авыл җирлегендәге Тәнгәчи торак пункты гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Лаеш муниципаль районы Рождествено авыл җирлегенең Тәнгәчи торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан һәм балачактан инвалидлардан тыш, 2024 елда үзара салым салу акчаларын 1500 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Тәнгәчи торак пунктында скважинаны проектлау һәм төзү

- Тәнгәчи торак пунктында Озерная урамында урам-юл челтәрен төзү, ремонтлау һәм тоту (смета буенча юл төзү: вак таш, асфальт сатып алу, нигез әзерләү, ташу, салу, килешү буенча эш өчен түләү)

3. Әлеге карарны Рождествено авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында игълан итәргә, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Рождествено авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: __________________ С.М. Гуцу
(имза) (имза расшифровкасы)

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Рождествено**
**авыл җирлеге Советы рәисе:** **С.М. Гуцу**